Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сәхрә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

26.10.2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "26" октябрендә 12 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сәхрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Шаршады авылында Зәйнетдинов урамы буенча, Сәхрә авылында Нариманов урамы буенча юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю);

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);

- Урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү;

- Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Шаршады авылы зиратын коймалау өчен материаллар сатып алу);

- Сәхрә авылының урамнарын кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 42 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 27 кеше кертелгән, бу 64% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 27 катнашучы тавыш бирде: "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сәхрә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда Шаршады авыл җирлеге территориясенең Шаршады авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Шаршады авылында Зәйнетдинов урамы буенча, Сәхрә авылында Нариманов урамы буенча юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю);

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);

- Урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү;

- Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Шаршады авылы зиратын коймалау өчен материаллар сатып алу);

- Сәхрә авылының урамнарын кардан чистарту.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы С.Л. Залетов

Совет Шаршадинского сельского поселения
Шаршады авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002540